**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Чубар-Абдулловского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Советская, д. 81 , село Чубар-Абдуллово
Азнакаевского муниципального района, 423323
Тел. (факс) (85592)38-7-37
Chabd.Azn@tatar.ru

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы
Азнакай муниципаль районы, 4233237
Тел. (факс) (85592) 38-7-37
Chab.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**01 ноябрь 2024 ел** **№6**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең Буралы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларынкертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Закон һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставы нигезендә карар чыгарам:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пунктында 2024 елның 15 нояберендә 11 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль Чубар-Абдул авыл җирлеге Буралы торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар, аларның гаилә әгъзаларыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- ремонт, коймаларны кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зират коймасын кору);

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Буралы авылы, Октябрь ур., 34 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: Н. Ә. Фәтхетдинов